КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 26

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 515 нче карары белән расланган Эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш табу максатыннан теркәлгән гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш табу максатыннан теркәлгән гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 15 июнь, 515 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 195 нче, 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче, 2020 ел, 30 май, 439 нчы, 2022 ел, 20 декабрь, 1382 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш табу максатыннан теркәлгән

гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында кулай эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә, 1.2 пунктның икенче абзацында «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин